ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2018 ел**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 197**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 январендәне «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ санлы Федераль законына, 2007 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 26 гыйнварындагы «2018 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 74 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче һәм 2 нче кушымталарда каралганча, Зеленодольск муниципаль районында 2018 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 5701, 31 сум итеп билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 144 номерлы карарын 2018 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 гыйнварындагы
197 номерлы карарына
1 нче кушымта

2018 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Мәетне күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,26 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны тәкъдим итү һәм китереп җиткерү | 3106,93 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару. | 885,06 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1625,06 |
| **Барлыгы** | **5701,31** |

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 31 гыйнварындагы
197 номерлы карарына
2 нче кушымта

2018 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,26 |
| 2. Гыйбадәт киеме кидертү/ Кәфенләү | 548,91 |
| 3.Табут һәм җирләү өчен башка кирәкле әйберләрне тәкъдим итү һәм китереп бирү | 2558,02 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәден) алып бару | 885,06 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1625,06 |
| **Барлыгы** | **5701,31** |